**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об образовании Экспортного совета Республики Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 21 апреля 2018 года № УП-326 «Об образовании Экспортного совета Республики Татарстан» следующие изменения:

а) в Положении об Экспортном совете Республики Татарстан:

в пункте 2.1:

абзац четвертый после слов «исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан» дополнить словами «, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан»;

дополнить абзацами следующего содержания:

«подготовка предложений для включения в документы стратегического планирования Республики Татарстан;

оценка состояния и определение направлений развития экспортного потенциала Республики Татарстан;

рассмотрение и утверждение:

отчетов по итогам работы куратора регионального проекта «Системные меры развития международной кооперации и экспорта в Республике Татарстан» не реже одного раза в полгода;

отчетов по итогам работы организаций, образующих инфраструктуру поддержки экспорта в Республике Татарстан;

отчетов о реализации программы развития экспортной деятельности в Республике Татарстан.

Отчеты, указанные в абзацах двенадцатом и четырнадцатом настоящего пункта, до их утверждения предварительно согласовываются с заместителем председателя Совета от предпринимательского сообщества.»;

пункт 3.1 дополнить абзацем следующего содержания:

«создавать рабочие группы по отраслевым и другим направлениям, связанным с осуществлением экспортной деятельности.»;

абзац второй пункта 4.1 изложить в следующей редакции:

«Совет формируется в составе председателя Совета, двух заместителей председателя Совета, секретаря Совета, являющегося куратором регионального проекта «Системные меры развития международной кооперации и экспорта в Республике Татарстан», и членов Совета, которые участвуют в его работе на общественных началах.»;

в пункте 4.2:

абзац первый изложить в следующей редакции:

«4.2. Председателем Совета является Президент Республики Татарстан. Заместителями председателя Совета являются Премьер-министр Республики Татарстан и представитель предпринимательского сообщества, избираемый членами Совета из своего состава.»;

абзац седьмой изложить в следующей редакции:

«В случае отсутствия председателя Совета его полномочия осуществляет один из заместителей председателя Совета, определяемый председателем Совета.»;

абзац четвертый пункта 4.3 дополнить словами «не менее чем за 10 календарных дней до даты заседания Совета»;

пункт 4.4 изложить в следующей редакции:

«4.4. Основной формой работы Совета являются заседания, которые проводятся по мере необходимости по решению председателя Совета, но не реже одного раза в квартал.»;

дополнить пунктами $4.4^1$–$4.4^3$ следующего содержания:

«$4.4^1$. Информация о предстоящих заседаниях Совета размещается на официальном сайте Центра поддержки экспорта некоммерческой микрокредитной компании «Фонд поддержки предпринимательства Республики Татарстан» и на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

$4.4^2$. Заседания проводятся публично и открыто, с обеспечением возможности личного участия в заседаниях представителей организаций, осуществляющих и планирующих вести экспортную деятельность на территории Республики Татарстан, не являющихся членами Совета.

$4.4^3$. Во время заседания Совета может осуществляться видео- и аудиозапись, а также трансляция заседания на официальном сайте Центра поддержки экспорта некоммерческой микрокредитной компании «Фонд поддержки предпринимательства Республики Татарстан» и на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

пункт 4.5 дополнить абзацем следующего содержания:

«Решение Совета принимается простым большинством голосов присутствующих на заседании членов Совета. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Совета является решающим.»;

пункт 4.6 изложить в следующей редакции:

«4.6. По решению председателя Совета решения Совета могут быть приняты путем проведения заочного голосования.

Уведомление о проведении заочного голосования и материалы, необходимые для рассмотрения вопросов, выносимых на заочное голосование, направляются секретарем Совета членам Совета не позднее чем за 10 календарных дней до даты подведения итогов заочного голосования.

Члены Совета в течение 10 календарных дней до даты подведения итогов заочного голосования представляют секретарю Совета в письменной форме свои решения по вопросам заочного голосования Совета. Непредставление членом Совета в указанный срок своих решений считается выражением согласия с представленными проектами решений Совета по вопросам, вынесенным на заочное голосование.

Обобщение поступивших в письменной форме решений членов Совета и подведение итогов заочного голосования осуществляется секретарем Совета.

Решение Совета считается принятым, если за него проголосовали более половины членов Совета, участвовавших в заочном голосовании. В случае равенства голосов решающим является голос председательствующего.»;

дополнить пунктами $4.6^1$ и $4.6^2$ следующего содержания:

«$4.6^1$. Решение Совета оформляется протоколом, который подписывается секретарем Совета и утверждается председательствующим на заседании Совета.

$4.6^2$. Утвержденный протокол в течение 7 рабочих дней с даты проведения заседания размещается на официальном сайте Центра поддержки экспорта некоммерческой микрокредитной компании «Фонд поддержки предпринимательства Республики Татарстан» и на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

б) состав Экспортного совета Республики Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания и распространяется на правоотношения, возникшие с 20 декабря 2021 года.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
29 декабря 2021 года
№ УП-1003

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «29» декабря 2021 года

№ УП-1003

**Состав**
**Экспортного совета Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Совета |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Совета |
| Хасанов Радик Шавкятович | генеральный директор акционерного общества «Производственное объединение «Завод имени Серго», заместитель председателя Совета (по согласованию) |
| Каримов Альберт Анварович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан, секретарь Совета |
| Абдулганиев Фарид Султанович | Уполномоченный при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей – помощник Президента Республики Татарстан |
| Агеев Шамиль Рахимович | председатель Союза «Торгово-промышленная палата Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Айдельдинов Айнур Тауфикович | директор некоммерческой организации «Инвестиционно-венчурный фонд Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Абдульзянов Артур Рашидович | председатель Татарстанского регионального отделения Общероссийской общественной организации «Деловая Россия» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Алешкин Валентин Осипович | директор общества с ограниченной ответственностью «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» (по согласованию) |
| Бакиров Газинур Тальгатович | помощник Президента Республики Татарстан |
| Баклашов Антон Николаевич | председатель Татарстанского республиканского отделения Общероссийской общественной организации малого и среднего предпринимательства «Опора России» (по согласованию) |
| Баширов Айрат Робертович | президент группы компаний «ДАНАФЛЕКС» (по согласованию) |
| Гайнов Артур Асхатович | руководитель Центра поддержки экспорта некоммерческой микрокредитной компании «Фонд поддержки предпринимательства Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Гараев Марат Масгутович | начальник Татарстанской таможни Приволжского таможенного управления Федеральной таможенной службы (по согласованию) |
| Гарипов Альберт Шамилевич | заместитель директора государственного бюджетного учреждения «Центр экономических и социальных исследований Республики Татарстан при Кабинете Министров Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Гинсбург Владимир Срульевич | управляющий директор акционерного общества «Казанский вертолетный завод» (по согласованию) |
| Дьячков Виктор Васильевич | председатель совета директоров акционерного общества «АйСиЭл-КПО ВС» (по согласованию) |
| Ереев Николай Викторович | руководитель представительства акционерного общества «Российский экспортный центр» в городе Нижний Новгород (по согласованию) |
| Зяббаров Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Капустин Евгений Николаевич | генеральный директор акционерного общества «Вакуummаш» (по согласованию) |
| Лаврентьев Александр Петрович | президент Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей) (по согласованию) |
| Минаева Наталья Андреевна | директор по региональному проекту акционерного общества «Российский экспортный центр» (по согласованию) |
| Минигулов Фарид Гертович | генеральный директор Казанского публичного акционерного общества «Органический синтез» (по согласованию) |
| Минуллина Талия Ильгизовна | руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан |
| Мистахов Ренат Искандерович | генеральный директор акционерного общества «Судостроительная корпорация «Ак Барс» (по согласованию) |
| Мифтахов Рафис Зуфарович | генеральный директор общества с ограниченной ответственностью «Казаньсельмаш» (по согласованию) |
| Рапопорт Ефим Фульевич | генеральный директор закрытого акционерного общества «Научно-инженерный центр «Инкомсистем» (по согласованию) |
| Сагдиев Ильнур Ильдарович | управляющий директор акционерного общества «Казанский завод компрессорного машиностроения» (по согласованию) |
| Садыков Марат Наилевич | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Салихов Айдар Раифович | генеральный директор некоммерческой микрокредитной компании «Фонд поддержки предпринимательства Республики Татарстан» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Самодуров Денис Викторович | генеральный директор акционерного общества «Республиканский агропромышленный центр инвестиций и новаций» (по согласованию) |
| Соловьев Сергей Владимирович | директор общества с ограниченной ответственностью «ДжиДиСи Сервисез» (по согласованию) |
| Файзрахманов Марат Джаудатович | первый заместитель министра финансов Республики Татарстан – директор Департамента казначейства Министерства финансов Республики Татарстан |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Хайруллин Айрат Ринатович | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Цыганов Василий Витальевич | исполняющий обязанности генерального директора акционерного общества «Внешнеторговая компания «КАМАЗ» (по согласованию) |
| Шагиахметов Мидхат Рафкатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр экономики Республики Татарстан |
| Шакиров Нур Хамзинович | генеральный директор акционерного общества «Казанский медико-инструментальный завод» (по согласованию) |
| Ширинов Адиль Шамиль Оглы | президент общества с ограниченной ответственностью «Соллерс Форд» (по согласованию) |
| Яруллин Рафинат Саматович | генеральный директор акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг» (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экспорт советы төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Экспорт советы төзү турында» 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-326 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Экспорт советы турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктта:

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларына кертү өчен тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасының экспорт потенциалын үстерү юнәлешләрен билгеләү һәм аларның торышын бәяләү;

түбәндәгеләрне карап тикшерү һәм раслау:

кимендә ярты елга бер тапкыр «Татарстан Республикасында халыкара кооперация һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары» төбәк проекты кураторының эш йомгаклары буенча хисапларын;

Татарстан Республикасында экспортка ярдәм итү инфраструктурасын булдыручы оешмаларның эш йомгаклары буенча хисапларны;

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген үстерү программасын гамәлгә ашыру турындагы хисапларны.

Әлеге пунктның уникенче һәм ундүртенче абзацларында күрсәтелгән хисаплар раслауга кертелгәнче эшкуарлар җәмгыяте Советы рәисе урынбасары белән килештерелә.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«экспорт эшчәнлеген тормышка ашыру белән бәйле тармак юнәлешләре һәм башка юнәлешләр буенча эш төркемнәре булдырырга.»;

4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Совет составына Совет рәисе, Совет рәисенең ике урынбасары, «Татарстан Республикасында халыкара кооперация һәм экспортны үстерүнең системалы чаралары» төбәк проектының кураторы булып торган Совет секретаре һәм иҗтимагый башлангычларда аның эшендә катнаша торган Совет әгъзалары керә.»;

4.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Совет рәисе – Татарстан Республикасы Президенты. Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм Совет әгъзалары үзләре составыннан сайлап алган эшкуарлар җәмгыяте вәкиле Совет рәисе урынбасарлары булып тора.»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Совет рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Совет рәисе урынбасарларыннан Совет рәисе тарафыннан билгеләнгән берсе башкара.»;

4.3 пунктның дүртенче абзацында «Совет утырышы уздырыласы көнгә кимендә 10 календарь көн кала» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Утырышлар Совет эшенең төп формасы булып тора, алар Совет рәисе карары буенча кирәк булган саен, ләкин кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.4$^{1}$– 4.4$^{3}$ пунктлар өстәргә:

«4.4$^{1}$. Советның булачак утырышлары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәгенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.

4.4$^{2}$. Утырышлар Татарстан Республикасы территориясендә экспорт эшчәнлеге алып бара торган һәм алып баруны планлаштыра торган оешмаларның Совет әгъзасы булып тормаучы вәкилләренең утырышта шәхсән катнашуы мөмкинлеген тәэмин итеп, әгъзаларның турыдан-туры һәм читтән торып катнашуы шартларында үткәрелә.

4.4$^{3}$. Совет утырышы барышында видеога төшерү һәм аудиога яздыру эше алып барылырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәгенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында трансляция оештырылырга мөмкин.»;

4.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Совет карары утырышта катнашучы Совет әгъзаларының гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.»;

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Совет рәисе карары буенча Совет карары читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

Читтән торып тавыш бирүне уздыру турында хәбәрнамә һәм читтән торып тавыш бирүдә карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча материаллар Совет секретаре тарафыннан читтән торып тавыш бирүгә йомгак ясаласы көнгә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Совет әгъзаларына җибәрелә.

Совет әгъзалары читтән торып тавыш бирүгә йомгак ясаласы көнгә кадәр 10 календарь көн дәвамында Совет секретарена язма рәвештә Советның читтән торып тавыш бирү мәсьәләләре буенча үз карарларын җибәрә. Совет әгъзаларының күрсәтелгән вакыт дәвамында үз карарларын җибәрмәве читтән торып тавыш бирүдә карап тикшерелгән мәсьәләләр буенча Совет карары проектлары белән килешүе дип санала.

Совет секретаре Совет әгъзаларыннан язма рәвештә килгән карарларны гомумиләштерә һәм читтән торып тавыш бирүгә йомгак ясый.

Совет карары читтән торып тавыш бирүдә катнашкан Совет әгъзаларының яртысыннан артыгы аны хуплап тавыш биргән очракта, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.6^{1}$ һәм $4.6^{2}$ пунктлары өстәргә:

«$4.6^{1}$. Совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Совет секретаре кул куя һәм Совет утырышында рәислек итүче раслый.

$4.6^{2}$. Расланган беркетмә утырышны уздыру датасыннан 7 эш көне дәвамында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәгенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында урнаштырыла.»;

б) Татарстан Республикасының Экспорт советы составын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 20 декабреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1003

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «29» декабрендәге
ПУ-1003 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Экспорт советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Совет рәисе урынбасары |
| Хәсәнов Радик Шәүкәт улы | «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Совет секретаре |
| Габделганиев Фәрит Солтан улы | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Агиев Шамил Рәхим улы | «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Әйделдинов Айнур Тәүфикъ улы | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Габделҗанов Артур Рәшит улы | «Эшлекле Россия» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Алешкин<br>Валентин Осипович | «П-Д Татнефть-Алабуга Пыяла җепселләр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Бакиров<br>Газинур Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Баклашов<br>Антон Николаевич | «Россиянең таянычы» кече һәм урта эшкуарлык гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Бәширов<br>Айрат Роберт улы | «ДАНАФЛЕКС» компанияләр төркеме президенты (килешү буенча) |
| Гайнов<br>Артур Әсхәт улы | «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясенең Экспортка ярдәм үзәге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гәрәев<br>Марат Мәсгут улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гарипов<br>Альберт Шамил улы | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Гинсбург<br>Владимир Срульевич | «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте идарәче директоры (килешү буенча) |
| Дьячков<br>Виктор Васильевич | «АйСиЭл-КПО ВС» акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Ереев<br>Николай Викторович | Түбән Новгород шәһәрендә «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыяте вәкиллеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Җәббаров<br>Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |

| | |
|---|---|
| Капустин<br>Евгений Николаевич | «Вакуумммаш» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Минаева<br>Наталья Андреевна | «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең төбәк проекты буенча директоры (килешү буенча)» |
| Миңнеголов<br>Фәрит Герт улы | Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллина<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Мистахов<br>Ренат Искәндәр улы | «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мифтахов<br>Рафис Зөфәр улы | «Казаньсельмаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Рапопорт<br>Ефим Фульевич | «Инкомсистем» фәнни-инженерлык үзәге» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәгъдиев<br>Илнур Илдар улы | «Казан компрессор машиналары төзү заводы» акционер җәмгыяте идарәче директоры (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Салихов<br>Айдар Раиф улы | «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе генераль директоры (килешү буенча) |
| Самодуров<br>Денис Викторович | «Республика инвестицияләр һәм новацияләр агросәнәгать үзәге» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Соловьев<br>Сергей Владимирович | «ДжиДиСи Сервисез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры |
| Цыганов<br>Василий Витальевич | «КАМАЗ» тышкы сәүдә компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шакиров<br>Нур Хәмзә улы | «Казан медицина инструментлары заводы» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Ширинов<br>Адил Шамил улы | «Соллерс Форд» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте президенты (килешү буенча) |
| Яруллин<br>Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |